КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 ноябрь г.Казань № 1200

2022 елда җирле үзидарә органнарының балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасының матди-техник базасын ныгыту өлешендә муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан финанслар белән тәэмин ителә торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) оештыру буенча йөкләмәләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елда җирле үзидарә органнарының балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасының матди-техник базасын ныгыту өлешендә муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан финанслар белән тәэмин ителә торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) оештыру буенча йөкләмәләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 11 ноябрь, 1200 нче
карары белән расланды

2022 елда җирле үзидарә органнарының балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасының матди-техник базасын ныгыту өлешендә муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан финанслар белән тәэмин ителә торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) оештыру буенча йөкләмәләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип 2022 елда җирле үзидарә органнарының балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасының матди-техник базасын ныгыту өлешендә муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан финанслар белән тәэмин ителә торган балаларга өстәмә белем бирүдән тыш) оештыру буенча йөкләмәләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы (алга таба – Минзәлә муниципаль районы) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү һәм тоту кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Субсидия Минзәлә муниципаль районының бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән, балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә.

3. Финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлеше – балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасы өчен җиһаз, инвентарь һәм җайланма сатып алу.

4. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы (алга таба – Министрлык).

5. Субсидия 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетында Министрлыкка каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен 2022 елда Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

6. Субсидия бирү шартлары:

Минзәлә муниципаль районының финанслашу максаты белән субсидия бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль хокукый акты булу;

Минзәлә муниципаль районы бюджетында (муниципаль берәмлек бюджеты-ның җыелма бюджет исемлегендә) финанслашу максатларында субсидия бирелә

торган Минзәлә муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен җитәрлек күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган субсидия күләмен кертеп) булу;

Минзәлә муниципаль районының финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча йөкләмәсе карала торган Татарстан Республикасы бюджетыннан Минзәлә муниципаль районы бюджетына субсидия бирү турында килешү (алга таба – гилешү) төзү һәм әлеге килешү белән каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

7. Субсидия алу өчен Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы Министрлыкка түбәндәге документларны җибәрә:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә заявка;

2022 елга Минзәлә муниципаль районының вәкиллекле органы карарыннан вәкаләтле зат тарафыннан таныкланган һәм Минзәлә муниципаль районы бюджетында Минзәлә муниципаль районының финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре аларны үтәүгә кирәкле күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган субсидия күләмен кертеп) булуын раслый торган Минзәлә муниципаль районы бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында өземтә;

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турындагы законнар нигезендә кыйммәте нигезләнгән җиһаз, инвентарь һәм җайланма сатып алу чыгымнары сметасын;

бу Тәртипнең 6 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән Минзәлә муниципаль районының муниципаль хокукый акты күчермәсен.

8. Бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документлар (алга таба – документлар) Министрлык тарафыннан кергән көнне аларның керү вакыты һәм датасы күрсәтелеп теркәүгә алына.

9. Документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык, алар кергән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия бирү һәм килешү төзү турында яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Субсидия Министрлык һәм муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы арасында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 20 сентябрь, 851 нче карары белән расланган Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 10 пунктына (алга таба – Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләре) таянып, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

11. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = P \times L,$$

монда:

P – бу Тәртипнең 12 пункты нигезендә билгеләнә торган балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасының матди-техник базасын ныгыту чыгымнары күләме;

L – Минзәлә муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 13 пунктында каралган тәртиптә билгеләнгән иң чик дәрәҗәсе.

12. Балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасының матди-техник базасын ныгыту чыгымнары күләме (P) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P = \sum_{v=1}^{n} N_v \times Q_v,$$

монда:

$N_v$ – җиһаз, инвентарь һәм җайланма кыйммәте;

$Q_v$ – җиһаз, инвентарь һәм җайланма саны;

v – җиһаз, инвентарь һәм җайланма төре;

n – җиһаз, инвентарь һәм җайланма төрләре саны.

13. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән хисаплылык нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече – балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмасын килешүдә каралган җиһаз, инвентарь, җайланма төрләре исемлеге һәм аларның саны нигезендә җиһазландыру.

15. Минзәлә муниципаль районының финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү өчен Минзәлә муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме, килешүдә билгеләнгән субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре зурлыкларына ирешү зарурлыгыннан чыгып, Минзәлә муниципаль районы бюджеты турындагы карар белән раслана (Минзәлә муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет исемлегендә билгеләнә).

16. Субсидияләр килешүдә билгеләнә торган тәртиптә һәм срокларда бирелә.

17. Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнары Министрлыкка килешүдә каралган формада, срокларда һәм тәртиптә җирле бюджетның финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре зурлыкларына ирешү турында хисаплар тапшыра.

18. Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнары тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм субсидияләрнең максатчан файдаланылмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

19. Килешүдә каралган йөкләмәләр бозылган очракта, Минзәлә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына акчаны кире кайтару һәм аларны алга таба файдалану тәртибе һәм шартлары Субсидияләрне формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләренең 15 – 18, 23 пунктларында билгеләнде.

20. Минзәлә муниципаль районы тарафыннан субсидия бирү шартлары бозылган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

21. Субсидиядән максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

22. Субсидиядән максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләтүгә китерә.

23. Агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидия Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының агымдагы финанс елында файдаланылмаган субсидиягә әлеге субсидиянең калган өлешеннән артмаган күләмдәге акчага ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә чираттагы финанс елында Минзәлә муниципаль районы бюджетының әлеге субсидияне бирү максатларына туры килә торган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Минзәлә муниципаль районы бюджеты керемenә кире кайтарылырга мөмкин.

Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемenә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.